

Татарлар арасында сату эше белән шогыльләнvчеләр борынгыдан килә. Бvген дә сатучы профессиясе донья кvләмендә ин популярлардан санала. Сату-алу эшләре елдан-ел кинәя, ә инде сатып алу һәр кеше тормышында аерым урында. Товар-акча монәсәбәтләренен яна торләре барлыкка килә һәм бу эштә катнашканнарга момкинчелекләре дә арта.
1966 елда СССРнын Югары Советы тагы бер бәйрәм ясады – День работников торговли. Шуннан алып бәйрәм коннәре ике тапкыр vзгәргән иде. 2013 елда Россия Федерациясе президенты Указы белән яна дата билгеләнә – июль аенын дvртенче шимбәсе (суббота). Бу профессия кешеләрен котлаулар vтте.      Шулай, Рузаевска районында бу сферада кvп кенә тырыш һәм булдыклы кешеләр хезмәт итә. Алар очен сатып алучыны профессиональ рәвештә канәгатьләндерv – топ бурычлары. Рафика Шигязам кызы Касимова эшмәкәр Анна Терентьева кибетендә кvптәннән эшли. Рафика Шигязам кызы кайнар килеш пекарнядан кибет киштәләренә килгән ипи белән чәй янына тәм-томнар сата. Белгәнебезчә, ипи – тормыш нигезе.
- Профессиямне бик тә яратам. Сатып алучыларым белән рәхәтләнеп аралашам һәм vзебезнен продукцияне дә теләп тәгъдим итәм. Башта ипи һәм батоннар гына сата идек, ә хәзер кабымлык һәм чәй янына пешкән әйберләр ассортиментыбыз бай. Барысы да бик тә тәмле, шуна кvрә сатып алучыларыбыз безнен ашамлыкларны теләп алалар. Житәкчебез унган; ул сатып алучылар теләген тынлый, кисәтvләрен булдырмаска тырыша һәм без анын ярдәменә һәрвакыт таянабыз; кешелекле. А.А. Терентьева сатып алучылар тәгъдимнәрен исәпкә алып ипи һәм кондитер әйберләренен ассортиментын vзгәртеп пешертә. Пекарнядан ипи турыдан-туры Рафика Шигязамовна саткан кибет киштәләренә менеп утыралар. Ә ипи пешерv артыннан кvзәтv тагы да кызыклы, торле-торле тәмлушкалар турында әйтәсе дә юк... Мәсәлән, формаларга салынган ипи камыры электромичкә кертелә. Берьюлы  бер стойкага 135 бодай яки арыш ипие сыя. Бодай ипие 32 минутта, ә арыш онынннан изелгән камыр бераз озаграк – 45 минутта пешvе турында белми идем. Пешкән ипи бераз ял итә. Аннары пекарнядан чыккан ипи беренче буларак Рафика Шигязамовна хезмәт иткән кибеткә кvчә.
Сатып алучылар һәрвакыт ипи һәм кондитер ашамлыкларнын сыйфатыннан канәгать; тәмле исләрен анкытып яна гына мичтән тошкән ипи ашыйсыларны китереп тора бит. Сатучысы да аларга бик ошый. Ул уалып торган печеньедан алып татлы пирожноеларга кадәр тәмлушкаларны тәгъдим итә; кемгә нәрсә ошый, шуны белеп бетергән инде. Һәрбер каприз ана закон, чонки сатып алучы канәгать булып китәргә тиеш икәнен яхшы

белә ул.
Анна хужабикә Терентьева кvнелен биреп хезмәт иткән коллектив турында:
- Наше предприятие существует с 2009 года и основной костяк работников до сих пор сохранен. Коллектив у нас очень дружный и работоспособный. Одна из старейших работниц – это Рафика Шигязамовна Касимова. Она трудится на предприятии с 2001 года, т.е. начинала еще у моего отца А.И. Овечкина, а с 2009 года работает у меня продавцом. За все это время Рафика Шигязамовна проявила себя как очень добросовестный и трудолюбивый человек. Она абсолютно неконфликтный сотрудник и пользуется большим уважением среди покупателей и коллег. Побольше бы нам таких работников.

**Н.Хәлил**